**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Сапеевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитеты**

ул. Школьная . 53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района, 423326
Тел. 8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

Мәктәп урамы, 53В, Сәпәй авылы
Азнакай муниципаль районы, 423326
Тел.8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«21» октябрь 2019 ел

**КАРАР**

№11

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 13.11.2017 ел №20 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документация әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында(10.05.2018 №11, 17.04.2019 №5 карарлар редакциясендә)

02.08.2009 ел №283-ФЗ «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар чыгара:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 13.11.2017 ел №20 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документация әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү тәртибенә (10.05.2018 № 11, 17.04.2019 № 5 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Территорияне планлаштыру буенча документлар кергән көннән соң егерме эш көне эчендә, аны раслау турында карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә кабул ителә, әлеге документацияне Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 10 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет территорияне планлаштыру буенча

документларны җәмәгать фикер алышуларында яки ачык тыңлауларда карауны тәэмин итә яки мондый документларны кире кага һәм аны эшләп бетерергә җибәрә.».

1.2. 2.10 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча җәмәгать фикер алышулары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 статьясындагы 12 өлешендә каралган очракта, шулай ук территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты карата әзерләнгән очракта үткәрелми:».

1.3. түбәндәге эчтәлекле 2.10.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.10.1. Әлеге Тәртипнең 2.9 пунктында күрсәтелгән территорияне планлаштыру проекты һәм (яки) территорияне межалау проекты, аерым өлешләрне раслау юлы белән, иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар мондый расланган өлешләргә карата үткәрелә.».

1.4. 2.12 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. . Башкарма комитет территорияне планлаштыру проекты, территорияне межалау проекты һәм җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, территорияне планлаштыру документациясен раслау турында Карар кабул итә яки мондый документацияне кире кага һәм иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылганнан соң егерме эш көненнән дә соңга калмыйча аны эшләп бетерергә җибәрә, ә әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар үткәрелмәсә, әлеге Тәртипнең 2.7 пунктында күрсәтелгән срокларда».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http/ / aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Ф.Г.Галиева